БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2019 Баулы шәһәре № 118

Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Баулы муниципаль районы бюджетына "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142нче маддәсе нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы бюджетына «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру очракларында). Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының норматив-хокукый актлары белән (алга таба - шәһәр Башкарма комитеты) билгеләнә.

2. Башка бюджетара трансфертлар Баулы шәһәр Советының "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында"гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә күрсәтелгән максатларга бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып шәһәр Башкарма комитеты тора.

4. Баулы муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасының Баулы шәһәр Советының “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлегенең тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында”гы карары белән раслана.

5. Башка бюджетара трансфертларның максатлары һәм тәртибе шәһәр Башкарма комитеты һәм район башкарма комитеты арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

б) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары;

в) башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) башка бюджетара трансфертларны күчерү графигы;

д) башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан район башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе һәм район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Район бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме, муниципаль берәмлекне сайлап алу критерийлары һәм шартлары шәһәр Башкарма комитетының норматив-хокукый актында билгеләнә.

11. Башка бюджетара трансфертлар Баулы муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен

ачылган территориаль органнары счетларына килешүдә билгеләнгән срокларда күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

13. Бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килгән елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә шәһәр Башкарма комитеты һәм районның финанс-бюджет палатасы башкара.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин